# Школьная газета «Тамчы»

Выпускается с октября 2008 года

Издаётся один раз в месяц



**Шеф редактор**: учитель татарского языка и литературы Шайдуллина Ландыш Камиловна



**Редколлегия**: Альмеева Резеда, Гарифуллина Аделя, Гильфанова Раиля, Шайдуллина Айгуль.







Мнение автора может не совпадать с мнением редколлегии.

**Рубрики**: “Медицинская аптечка”, “Новостная лента”, “Творчество юнкоров” или “Ижат бите”, “Моя жизнь”, “Галерея”, “interview”.

**Приём материала** (статей, рассказов, стихов, рисунков и др.) осуществляется через членов редколлегии или шеф-редактора (307 кабинет).

Вследствие того, что ученики временно получают образование в Джалильской школе №1 и гимназии, мы так же временно приостанавливаем нашу деятельность — деятельность журналистов и педагогов. Скажем “стоп” и многочисленным конкурсам нашей газеты и школы. Но ненадолго! Специально для вас будут выпускаться номера, подготовленные специально отведённым темам. Сегодняшний номер — это номер, посвященный военно-патриотической теме.





## *СОРАШТЫРУ…. СОРАШТЫРУ… СОРАШТЫРУ…*

## *УКЫТУЧЫЛАРЫБЫЗ НИ УКЫЙ?*

Бүгенге сораштыруны үздырганда, без, әлбәттә, китап, матбугат укуның укытучылар өчен никадәр мөһим икәнен белдек. Әйдәгез, кайберләре белән танышыйк әле.

Рус теле һәм әдәбияты укытучысы **Сәрия Әмир кызы**: «Вакытлы матбугат арасында “Ватаным Татарстан”, “Сарман”, “1000 советов” газеталарына өстенлек бирәм. Иң яраткан китабым — И. Тургеневның «Дворянское гнездо» әсәре. Гомумән, иң яраткан авторым — Тургенев ул. Аның әсәрләрен бик яратып укыйм».

Рус теле һәм әдәбияты укытучысы **Ильмира Зөфәр кызы:** «Г. Ибраһимов иҗатын яратам, иң ошаган әсәре — “Адәмнәр” дип атала. М. Булгаковның «Собачье сердце», “Мастер и Маргарита” әсрләрен яратам. Өйдә «Татарстан яшьләрен”, “Ватаным Татарстан”, “Сарман”, “Юлдаш”, “Салават күпере”, “Непоседа” газета-журналларын алам».

Технология укытучысы **Ирина Николай кызы:** «Сезнең кебек күзләр яңып торганда, яңа белемнәрне арттыру максаты белән китаплар укырга бик яраткан идем. Бик күп укыдым. Теодор Драйзерның китаплары кызык иде миңа. Газета-журналларга язылмыймын».

Тарих укытучысы **Илсөяр Мөҗәһит кызы:** «Иң яраткан китабым — «Граф Монте-Кристо». Соңгы вакытта китапларны укырга бөтенләй вакыт юк, әмма аларны укырга тырышам. Гаиләбез белән “Нефтяник Джалиля”, “Сарман”, “Ялкын»га язылдык”.

### «Ел китабы—2014» конкурсы нәтиҗәләре

Чәчмә әсәрләр:

I урын - Мәдинә Маликова «Арыш тәме»;

I I урын - Халисә Ширмән «Ерактагы йолдызым»;

III урын - Альберт Хәсәнов «Данәгөл».

Балалар әдәбияты:

I урын – «Тукай иленә сәяхәт=Путешествие в мир Тукая»;

II урын – «Әкиятләр»;

III урын – Булат Садретдинов «Айда кунакта».

**Тезмә әсәрләр:**

I урын – «Күбәләгем, түгәрәгем»;

II урын – Шәрифуллина Эльмира «Тамды яшем»;

III урын – Роберт Миңнуллин «Татарларым».

### *Дөньяда иң күп укыла торган 10 китап*

10 иң күп укыла торган китаплар исемлеге соңгы 50 ел эчендә бастырылып чыгарылган һәм сатылган китаплар арасыннан алынган. Шартлычы, әгәр китап басылмаса, димәк, ул укылмый дигән фикер йөртелә.Һәм китаплар исемлеге түбәндәгечә:





1. Библия
2. «Цитатник» Мао Цзэдун
3. «Гарри Поттер» Джоан Роулинг
4. «Властелин колец» Дж. Р.Р.Толкиен
5. «Алхимик» Паоло Коэльо
6. «Код да Винчи» Дэн Браун
7. «Сумерки» Стефани Мейер
8. «Унесенные ветром» Маргарет Митчелл
9. «Думай и богатей» Наполеон Хилл
10. «Дневник Анны Франк»



## ЕСТЬ ТАКАЯ ПРОФЕССИЯ - РОДИНУ ЗАЩИЩАТЬ

**Р.К.Талибуллин,** капитан, руководитель команды допризывников



В России во все времена военная служба была делом чести, школой мужества и самоотверженности, а к профессии военного всегда относились с особым почетом и уважением. Однако она не каждому по силам. Для этой профессии очень важны целеустремленность, стойкость духа, умение бороться со всеми трудностями, так как профессия не из легких. Действительно, в современной жизни далеко не каждый молодой человек выбирает военную службу. Этому виной и закрепившаяся за профессией негативная репутация. Парни в основном думают о том, как бы избежать армии, боясь дедовщины и прочих ужасов, о которых так часто говорят. Причина в том, что снижен престиж армии. Если раньше косо смотрели на тех, кто не служил, то сейчас действует обратный принцип. Это не правильно. И хорошо, что еще остались ребята, которые идут в армию и понимают, что их долг – служить Родине, и что армия готовит настоящих мужчин.

Военная карьера начинается с хорошего образования, поэтому молодые люди, решившие связать свою жизнь с этой профессией, еще учась в школе, должны задумываться о выборе учебного заведения.

**КСТАТИ.** Профессия военного не является чисто мужской, как это принято считать. Среди женщин военное дело также востребовано. Как показала игра «Есть встать в строй - 2015”, девушки вполне справляются и строевым шагом, и многочасовыми маршировками, тренировками, и физическими нагрузками. Спасибо нашей команде за красивую победу. Так держать!

Всех ребят, коллег-мужчин сердечно поздравляю С Днем защитника Отечества и желаю мужества и бодрости духа.



# Тамчы

Школьная газета МБОУ “Джалильская СОШ №2”

№6 (февраль) 2015 г.

## *«ЕСТЬ ВСТАТЬ В СТРОЙ!»*

26 февраля в ДК посёлка Джалиль прошло всеми долгожданное событие — военно-патриотический конкурс “Есть встать в строй”. В конкурсе участвовали учащиеся старших классов 6-ти команд: Джалильских школ, двух Сармановских, ПТУ. Наша команда оправдала надежду многочисленных болельщиков, в лице учащихся школы и всех учителей, технического персонала, родителей.

Уже седьмой год подряд наши ребята занимают призовые места. Магалимов Радмир-лучший командир, лучший по сборке и разборке автомата, Макаров Максим - самый меткий стрелок, Саитов Ислам - лучшее подтягивание, Биктимиров Айнур - самый быстрый и самый ловкий в одевании защитного комплекта. Также в команде были Валиев Тимур, Валиев Раиль, Мирвалиев Раиль, Мухаметшин Ильвир. А изюминкой нашего конкурса была – Целипкова Инна.

**Парламент школы**

Это было ДО...



**Дарья ЩЕРБАКОВА**, член парламента: «Прежде всего я хочу пожелать им удачи! В этом году соперников побольше и сил придется приложить в 2 раза больше! Но думаю, ребятам это не помеха, наши бойцы смогут справится со всеми трудностями. Главное, чтобы присутствовал командный дух. А мы, болельщики, всячески будем поддерживать их из зала и болеть!»

# ЯҢА РУБРИКА
# “БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫ МИНЕМ ГАИЛӘМ

## ИСТӘЛЕККӘ КАЛГАН ИКЕ ТОЛЫМ

Минем карт әбиемнең апасы Мөзәянә Мәгъдәни кызы Мәгъдәниева - Бөек Ватан сугышы ветераны, ир-егетләр белән иңгә-иң торып туган илебезне фашист илбасарларыннан яклаган батыр сугышчы, 46 ел хезмәт стажы булган хезмәт ветераны, орденлы укытучы иде.

Сугыш башланганда ул урта мәктәне генә тәмамлый. Менә шундый япь-яшь, чандыр кызга шулкадәр көч һәм батырлык кайдан килде микән? Әтисе Мәгъдәни бабай сугышка китүгә, ул да фронтка җибәрүләрен сорап военкоматка бара. Тик аны алмыйлар, ул кире авылга кайта. Тагы бара, тагын боралар. Колхозга эшче көчләр бик кирәк була, Мәгъдәни бабайсыз өйдә бер генә ир-ат булмавы да үзен сиздерә. Мөзәянә әби бөтен көчен биреп тырыша, ә үзе фронтка китү, дошманнарны тизрәк җиңү турында хыяллана. Аның хыялы 1942 елда чынга аша. Кыз, әнисенә һәм кыз туганнарына озын толымнарын истәлеккә калдырып, сугышка китә.



Аның сугышчан юлы ике ел, җиде ай, унбиш көнгә сузыла. Ничә мең чакрым юлларны, бихисап авырлыкларны, үлем дәһшәтен, югалту ачысын, дошманга карата ярсу-нәфрәтне бергә туплаган еллар, айлар, көннәр булалар алар. Балтыйк буе фронтындагы зенит полкында ПУАЗО приборчысы булып хезмәт итә Мөзәянә әби, шунда партия сафларына кабул ителә. Туган авылына 1945 елның 20 августында кайта. Миллионлаган кешенең гомерен өзгән, миилионнарча хатынны тол, миллионларча баланы ятим иткән бу сугыштан ирен дә, сөекле кызын да исән-сау килеш каршы алган карт әбиемнең әнисе Мәгъдәнә әбинең шатлыгы чиксез була.

1947 елдан Мөзәянә әбием мәктәптә эшли башлый. Укытучы хезмәтенә ул 32 елга якын гомерен бирә. Ерак илләрне, чит җирләрне күреп, җәяүләп узганга күрә, бәхетне читтән эзләми: туган авылында кала, намуслы хезмәт куя, тормыш кора, дүрт бала тәрбияләп үстерә. Тик менә аның ире, үзе кебек үк фронтовик, мең үлемне җиңеп туган ягына исән-имин кайта алган Миргалим бабай гына балаларын һәм хатынын ялгыз калдырып үлеп китә. Бу вакытта Мөзәянә әбиемә бары 40 яшь кенә була. Ул тагы сынмас һәм сыгылмас өчен бар көчен, сабырлыгын туплый.

Менә шулай гомер буе көрәшеп яшәгән намуслы, батыр туганнарым белән мин бик горурланам.

**Ильмир Зәкиев, 8 А сыйныфы укучысы**

## ИСТӘЛЕККӘ КАЛГАН СОҢГЫ ХАТ

Ачы сугыш безнең гаиләне дә урап узмаган. Минем дүрт карт бабам да катнашкан анда. Ике әбиемнең, ике бабамның да әтиләре илебезне дошманнардан саклау өчен кулларына корал алганнар һәм шул китүдән исән-имин туган якларына, сагынып көткән балалары янына кайта алмаганнар.

Әниемнең әнисе Гөлнур әбием хәзерге Зәй районы Сармаш по Ирне авылында туган. Мин әле Гайнелхәят әбинемне бик аз гына хәтерлим. Тик менә карт бабамны күзалларга аның ике фоторәсеме һәм бер хаты гына мөмкинлек бирә. Алар безнең гаиләбезнең иң кадерле истәлеге. Бабам сугышка соңрак, бары 1943 елда гына китә.Ул бик оста комбайнчы була. Шуңа күрә аны өч тапкыр кире боралар, бронь бирәләр. Ә соңгы баруында инде повестка тоттырып җибәрәләр.



Бабамның хаты инде саргаеп беткән, ертылырга гына тора. Тик ул безгә бик кадерле. Бу хат аша гүя миңа Бөек Ватан сугышчысы эндәшә. Мин еллар аша Йосыф бабамның тавышын ишетәм күк. Хатны тыныч кына укып та булмый. Аның һәр җөмләсеннән бабамның чиксез сагынуы күренә. Авылдашларына, гаилә әгъзаларына сәлам юллаган ул, һәрберсенең аерым хәл-әхвәлен сорашкан. Сугышка киткән туганнарының хәлен-хәбәрен беләсе килгән аның.

Карт бабам шушы хатны язганнан соң бары 2 генә ай яшәгән. Кара тышлы "Хәтер" китабының 3 томында мондый мәгълүмат бирелгән: "Миннегулов Йосыф Миңнегол улы 1944 нче елның 26 июнендә Белоруссияне азат иткәндә һәлак булган". Карт әбиемә килгән үлем хәбәрендә бабамның күмәргә гәүдәсе калмавы турында хәбәр ителгән була. Алар урнашкан окоп өстенә снаряд төшкән, шуңа күрә анда булучыларны күмә дә алмыйлар...

Үсә барган саен мин хат юлларына салынган мәгънәне тирәнрәк ачам. Сагыну, тормышны чиксез ярату, туган илгә тугрылык, ата мәхәббәте, кайгыртучанлык һәм бик тә, бик тә яшисе килү теләге белән сугарылган икән бит ул бердәнбер һәм соңгы хат.

Гадел Кутуйның "Сагыну" нәсерендә мондый юллар бар: "...Сагынган саен сагынасы килә. Сагынуым шундый көчле булганга, кайтуым да ышанычлы. Кайтыр булмасам, бу кадәр сагынмас идем..."

Сугышта җиңү өчен безнең илебез бик кыйммәт түләде. Башка мондый мәхшәрләр кабатланмасын, бабаларыбыз, әтиләребез гел безнең янәшәбездә булсын, кан түгелмәсен, яшь коелмасын иде.

**Айгөл Шәйдуллина, 7 А сыйныфы укучысы**

## Они защищали Родину!

Более полувека назад, в 1941 году, на нашу страну напали фашистские войска. Весь народ поднялся тогда на защиту Родины! Подвиг людей, защитивших нас, их потомков, никогда не будет забыт!



Как забыть пролитую ради нашей свободы и счастья кровь? Как забыть подвиг наших прадедушек и прабабушек? Их ежедневный военный труд так же достоин восхищения и преклонения, как и отдельные героические подвиги, о которых



написаны книги и сняты фильмы!!!

Защищали Родину не только на фронте, но и в тылу. Без миллионов и миллиардов женщин, подростков, специалистов, работавших в тылу на военных заводах, на полях, на фабриках не состоялась бы наша победа! Поэтому уже давно эти люди приравнены к полноправным участникам Великой Отечественной войны.

Дело освобождения Родины было всенародным, поэтому когда мы говорим: «Они защищали Родину», мы должны иметь вв виду всё военное поколение, всех людей, воевавших и трудивших в то время.

Вечная им память и слава!

## Что такое война?

Что же такое война, иногда задумываюсь я. По рассказам Ильсияр Музагитовны, учительницы истории, я поняла. **Война — это то, что разрушает, что всё уничтожает.**

Одной из самых страшных войн в мире была Великая Отечественная война. На классном часу мы говорили про блокаду города Ленинграда. Я слушала все с замиранием сердца.

10 июня 1941 года фашисты предприняли первую попытку овладеть сходу городом. Многие солдаты, в их числе и мой прадед, обороняли город. Немецкие войска превосходили наших по числу танков и боевых самолётов и имели равенство в артиллерийских орудиях, миномётах. Блокада города продолжалась 900 дней. Люди исхудали, болели, умирали.. Выход немецких танков и пехоты на подступы к Ленинграду привёл к необходимости с целью



лучшего управления войсками разделить северный фронт на два фронта: ленинградский и Карельский. Памяти жертв блокады и погибших участников обороны Ленинграда посвящены в городе мемориальные ассамблеи Пискарёвского и Серафимского кладбищ.

Героическая эпопея защиты Ленинграда не померкла сейчас, и не померкнет веками. История Ленинграда учит беззаветно любить своё Отечество и воспитывает молодое поколение!

Я горжусь тем, что являюсь потомком народа, который избавил человечество от фашизма, подарил жителям Европы мирное небо, а нам вернул свободу. Я горжусь своим дедом, так как он один из



таких героев.

**Раиля ГИЛЬФАНОВА, член редколлегии.**

## САМОЕ СТРАШНОЕ СЛОВО В МИРЕ

Я думаю, слово война — это самое страшное слово в мире. Это слово напоминает нам о больших потерях в семьях, потому что ни одна семья не осталась без потерь. У кого-то погиб папа, дедушка, сын, жених. Никому бы не хотелось испытать такую учесть. При слове война ветераны начинают плакать и вспоминать кошмары этих ужасных годов.

Я бы хотела, чтобы больше таких страшных войн между странами не начинались. Пусть в мире будет мир, рождаются и играют дети, поют птицы, звучат веселые песни. Не этим ли прекрасен мир?!

**Айгуль ШАЙДУЛЛИНА, 7А**



В Сармановском районе есть небольшая деревня Иске Кэшер – Старокаширово. Старокаширово было основано на очень красивом месте, на берегу небольшой речки Кэшер, что в переводе обозначает "Каменистая река", так как берега и дно этой реки усыпаны мелкими камнями. Здесь 16 ноября 1916 года в семье Хасановых родился сын. Назвали его Зиннатулла. В переводе это означает "Божий дар, подарок, ценность". Так написано в рукописной тетради деревенского муллы, а автобиография героя начинается со слов: "Я, Хуснуллин Зиннат", в документах их немецкого архива про него пишут: "Хасанов Зиннат".

Его детство ничем не отличается от детства других детей того времени. Он помогает своим родителям по хозяйству. Отец Хуснулла, мать Ханифа поведали очень много горя, так как похоронили своих пятерых детей в младенчестве. У Зиннатуллы был брат Мухлисулла (погиб на фронте), братишка Шафигулла, сестры Рокия и Асия. Они были дружны между собой и едины. Как и все дети деревни, они летом ходили купаться на речку, собирали малину, черемуху, щавель в Кутемелинском лесу. Так называли и называют лес, который находится недалеко от этой деревни. Он был очень богат и не дал умереть от голода жителям многих близлежащих деревень. А зимой все катались с горы и на льду речки. Зиннат особенно любил ходит на берегу любимой реки. Здесь он собирал прудья, а дома делал из них красивые и аккуратные корзины. В воспоминаниях односельчан мы читаем такие строки: "Зиннат очень любил читать стихи, любил петь". В письмах Латыйфа апа (жена брата) очень много стихотворных строчек, написанных героем. Было еще одно увлечение героя. Он любил подниматься и часами сидеть на самой вершине горы. Здесь он встречал рассвет, здесь мечтал о подвигах. На одном из камней была найдена надпись: "Зиннат Хасанов.1916-1936." Эту запись он оставил когда уезжал в Казань. Информацию про детство и юность героя можно узнать из воспоминаний учителя истории, аксакала этой деревни Асгата Гарифуллина. Эти записи хранятся в музее. Асгат абый пишет: "Зиннат с маленьких лет начал помогать всем. У него были золотые руки. Мальчик все время что-то мастерил. Сперва научился плести корзины, потом занялся ремонтом ведер, самоваров, мисок. Не только чинил, даже делал какие-то узоры на них. Потом начал работать топором. С родственниками построили сарай. Кое-что он делал на продажу". В музее очень много экспонатов, которые сделаны его руками.

В 1936 году Зиннат Хасанов приехал в Казань. Юноша хотел учиться и поступил в техникум советской торговли. Был активистом, любил спорт, отличался готовностью помочь, организаторскими способностями, целеустремленностью. Его избрали в комитет комсомола. Вот этими качествами и взглядами на жизнь очень схожи два героя: Муса Джалиль и Зиннат Хасанов. Хотя парень не писал стихи, он умел их пламенно читать и играть на гармошке. После техникума парня направляют в город Киров. В 1939 году был призван в ряды Советской армии. В начале службы парня отправляют в курсы младших командиров в г. Канское военное училище. Но долго учиться он не смог. Началась война и курсант сразу ушел на фронт. После этого известий от него почти не поступали, вскоре он совсем пропал. Родным он отправил всего одно письмо, где сообщил о том, что их дивизия находится под Брянском. Зиннат Хасанов был ранен около села Спассово Московской области и попал в плен. Только спустя 13 лет после его смерти стало известно о том, что он был членом подпольной организации и сражался против фашистов.Эта подполная организация была организована в польском крепосте Демблине. Сюда фашисты стали собирать военнопленных татар, башкирцев и других восточных национальностей. Они хотели создать национальные военные полки и направить их на фронт, чтобы они уже воевали в них стороне. Вот в таких условиях Гайнан Курмаш и Фоат Сайфулмулюков создают свою подпольную организацию. Вскоре сюда принимают и Зинната Хасанова. Потом к ним присоединяется татарский поэт Муса Джалиль. Они устанавливают связь со всеми лагерями на территории Польши. Зиннату Хасанову было поручено очень ответственное задание. Он был связным-посредником между пленными, которые находились в концлагерях Берлин, Узедом, Едлино, Крушино, Седльце, Дрезден, Родом, передавал им последние сводки "Совинформбюро" и устанавливал новые связи. Это было очень сложно и смертельно опасно, но парень не боялся смерти.

Но нашелся предатель и начались аресты. У Зинната Хасанова в подушке нашли пачки листовок. Его пытали трое суток... После этого друзья его не узнали: его волосы стали седыми, лицо изуродовано, тело избито. Но он выдержал, молчал, никого не предал. После ареста их некоторое время держали в концлагере Шпандау, потом Плетцензее и Моабит. В марте 1944 года Дрезденском концлагере состоялся суд. Военный суд приговорил всех членов этой организации к смерти. И 25 августа 1944 года в концлагере Плетзенцее они были казнены. 114 шагов нужно было пройти этим мужественным защитникам нашей родины от камеры до гильотины. Они прошли его гордо подняв головы и улыбаясь, зная, что жизнь у них была короткой, но смерть прозвучит как песня, зная, что будут они жить и после смерти.

**Мардамшина Лиана, Шаймухаметова Аделя, 9 а**







Музей встречает нас вот таким портретом нашего земляка.

На шкафах альбомы с воспоминаниями односельчан.





Письма Шарипова А.А., однокурскника по военно-полевым курсам



Фотостенды рассказывают о родственниках героя







***Ябалактау!***
***Исеме җыр сорамый,***
***Сандугач та түгел, лачын да.***
***Тора ул тау ачып таш күкрәген***
***Бәйгедәге җилләр каршында.***
***Хәтерли ул көләч Биктимерне***
***Һәлак булган Хасан күлендә.***
***Ташта калган имза инде күчкән***
***Нәни авылдашлар теленә.***
***Сарман көен җырлап, Зиннәт китә,***
***Егет кичә утын-ялкынын.***
***Җыр өзелә, җыр дәвамын дуслар***
***Алып кайта Берлин аркылы.***





Зиннат Хасанов был умелым кузнецом, плотником, любил читать стихи, часто поднимался на вершину Ябалактау и любовался красотой родного края. Быть может он уже тогда мечтал о подвиге...



# «ЯЛКЫН» ПИТЕРГА КИТЕРЕР» БӘЙГЕСЕНЕҢ ФИНАЛЫНДА

5 февраль көнне Казандагы «Сәләт йорты” нда “Ялкын Питерга китерер!” бәйгесенең бүләкләү тантанасы үтте. Биредә “Ялкын” журналына язылган сыйныфлар җыелышып, үзләре белән таныштырды, чыгышларын күрсәтте һәм бүләкләр отты. Катнашкан класслар 2015 елның беренче яртыеллыгына “Ялкын” журналына язылып, үз классларын үзенчәлекле таныштырырга тиеш иде. Һәм, әлбәттә, презентацияләрен, квитанцияләрен җибәрергә. Үз материалын юллаган класслардан жюри җиңүче 4 сыйныфны сайлады: Сарман районы 2нче санлы Җәлил урта мәктәбеннән 7А сыйныфы, Яңа Чишмә районы Тубылгытау мәктәбенең 8нче классы, Апас районы Каратун мәктәбенең 7нче, Кайбыч районы Бәрлешбаш мәктәбенең 6нчы классы.

Мәктәбебезнең 7А сыйныфы укучыларын бүләк — диплом һәм ноутбук көткән иде. Шулай ук алар «Ак калфак» ТР Хатын-кызлар җәмгыятеннән бүләкләр оттылар.

**Резидә ӘЛМИЕВА, 7А**

“Ялкын” журналының әдәби редакторы Ләйсән ФӘЙЗУЛЛИНА фотолары.















# СУГЫШТА ТҮГЕЛ, СУГЫШНЫҢ ҮЗЕН ҖИҢӘРГӘ КИРӘК




Сугышны үз күзләре күргән кешеләр саны көннән-көн кимесә дә, ул дәһшәтле көннәрне бездән аерып торган еллар саны арта барса да, бу мәхшәр халкыбыз йөрәгендә сагыш, ут һәм мәңге бетмәс хәсрәт уты булып яна. Өлкәннәр, үзләре сабый гына булган әби-бабайларыбыз, ветераннарның хатирәләре аша беләбез без бу турыда, фильмнар, күртөрле әсәрләр сөйли аның хакында, рәсемнәр күзалларга ярдәм итә. Аларның һәркайсында күз яше, авырлык, үлем...

Ә бит истәлекләр буенча 1941нче елның 22 июнь иртәсе искиткеч матур, аяз була. Менә шундый гүзәллекне бозып, илебезнең аяз күгенә дошман самолетлары керә. Канатларында үлем алып керә алар! Сугышка әзер булмауга карамастан, халык яуга күтәрелә. Теләк бер генә: илебезне, яраткан Ватаныбызны саклап калырга, аны фашистларга берничек тә бирмәскә! Бирмәскә! Бирмәскә!



Илебез җиңү өчен яши башлый. Һәркем шундый теләк, өмет белән яши. Бу ышаныч кешеләргә көч бирә. Фронтта тиңдәшлек батырлыклар кылына. Хезмәт фронтында да сынатучылар булмый.

Бу турыда сөйләшүләр оештырганда очрашуга килгән өлкәннәр үзләренең күз яшьләрен тыя алмыйлар. “Мин моны күрдем! Без боларны кичердек, - диләр алар. – Без әтием дип бер тапкыр да әйтә алмаган балалар буыны бит”. Әтиләренең көчле кулларын тою бәхете эләкми аларга. Елаганда юатыр кешеләре дә, усаллардан саклар кешеләре дә әниләре генә була. Әниләрнең юатып торырга вакытлары булганмы? Алар ирләре урынына басуда, урманда, заводларда хезмәт куйганнар, тик сынмаганнар. Бу буын әби-бабайларының бүген дә өметләре бер: Җиңүгә ышаныч. Сугыш уты кабызырга теләүчеләр акылларына килерләр, Җирне тынычлык аша гына саклап калып булганын аңларлауларына ышанып яшиләр алар. Киләчәгебез якты булсын өчен, бүген кешелеккә сугышта түгел, ә сугышның үзен җиңәргә кирәк бит.

**Резидә ӘЛМИЕВА, 7А**



# ФОТОРЕПОРТАЖ ТРАДИЦИОННОГО КОНКУРСА «ЕСТЬ ВСТАТЬ В СТРОЙ»

















